


ISSN 0868-4545

# Салават күпере



# Аюның



Аюның туган көне,
Күп кунаклар җыелды.
Бүләкләре мул булды,
Онытылмасын иде бу юлы.

Җырладылар кунаклар
Һәм танцават иттеләр.
Бии-бии, арып-талып,
Буталышып беттеләр.

© "Салават күпере", 2002 ел

# Туган көне

Узды-китте көн бик тиз,
Арыдылар төштән соң.
Карыйк әле, туган көнгә
Кемнәр килде икән соң?

**БҮ – ТӨ – РЕ – ЛКЕ,**
**КЕР – КҮ – ПЕ – ЯН,**
**ТИ – ТУК – ЕН – РАН...**




*Рәссам Лилия* ЗОЛОНДИНОВА






Вакыт иленә сәяхәт

# Көндезге бер –



– Хәерле иртә, кызым! – диде Алсуга әнисе. – Хәерле Яңа ел иртәсе!


Яңа ел! Өр-яңа ел! Бүген Яңа елның беренче иртәсе. Шуңа күрәдер, бу иртә башкаларына охшамаган, аерым, серле тоелды Алсуга. Ул сәгатькә карады. У-у, йоклаган икән – сәгать инде 10 тулып килә. Кичә соң яттылар шул. Сәгать 12 тулганны көтә-көтә арып бетте Алсу. Кызык инде, Яңа ел нәкъ төнге сәгать 12дән башлана икән.




– Яңа ел гына түгел, яңа көн дә шулай башлана. Төнге 12 түгел, 00 сәгать, яңа тәүлекнең башы була инде ул, – дип аңлатты әтисе.

– Нәрсә соң ул тәүлек? – дип сорады Алсу.

Сәгатьне тәмам өйрәнеп беттем дип уйлап йөри иде инде ул. Юк икән. Алсу белмәгән серләре бар икән әле. Көндезге 12дән соң, көндезге 1, 2, 3... дип саный иде ул. Ә дөресрәге, 13, 14, 15... сәгать икән.







*Механик сәгатьләр моннан якынча 600 ел элек уйлап табылган. Башта алар бик нык «алдашканнар».*

*Моннан 300 ел элек, маятникны уйлап тапканнан соң, вакытны төгәлрәк күрсәтә башлаганнар.*



# Унөч сәгать

Әтисе аңа менә шундый сәгать ясап күрсәтте.

Әтисенең электрон сәгатен төшенә алмый йөдәгән иде, хәзер аңлады менә.




Сез дә аңладыгызмы, дусларым?

Аңласагыз, әйдәгез, үзегезне тикшереп карагыз әле. Рәсемдәге бу механик сәгатьләрнең электрон парларын табыгыз.

Ә тәүлек нишләп нәкъ менә 24 сәгать соң? Көн ничек туа, ни өчен төн җитә?

Бу хакта журналыбызның алдагы саннарында сөйләшербез.

***Төшке аштан соң берничә сәгать вакыт үткәч, синең ашыйсың килә башлый. Димәк, кичке аш вакыты җиткән. Тагын берничә сәгатьтән арыганыңны сизәсең һәм йокларга ятасың.***

***Безнең организм вакыт буенча яшәргә күнеккән.***

*Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА*









**Ләбиб Лерон**

# Сәлим улы Хәлим

*Рәссам*
*Фәрит Муллахмәт*

Шалтмылтфильм

Минем, ис-акылым китеп,
Шаккатып торган мәлем:
Ни генә уйлап чыгармый
Сәлим малае Хәлим!

Бүген дә бик шәп-шәп уйлар
Килде аның башына:
«Ә» дигәнче ясады ул
Тәгәрмәчсез машина!



Хәзерге зур самолетлар
Булып чыкты – яраксыз...
Ул ясаган самолетлар
Оча күктә... канатсыз!



Кайбер малай-шалайларның
Очасы бик килсә, дип,
Ясады өч тәгәрмәчле,
Ак канатлы вилсәпид!



Торган саен аның башы
Шәбрәк эшли башлады:
Сыер, сарык көтәр өчен
Робот ясап ташлады!



Ул ясаган көймә-кораб,
Шаклар катарлык – күрсәң:
Моторсыз йөзә дә китә...
Ике тапкыр төчкерсәң!



Ул ясаган тимер атлар
Тыр-тыр-тырылдап чаба...
Сапсыз-җепсез кармакларга
Балыклар җырлап каба!



Ул ясаган өй-йортларның
Һәммәсе дә аяклы;
Кайберләре генә никтер
Аяклы да таяклы!



Сәлим малае Хәлимнең
Һәр эшкә кулы ята:
Ул ясаган чаңгыларда
Запаска өчәр ката!



Ул ясаган чаналарны, –
Күрсәң – исең китәрлек:
Тауга каршы, – «әһ» дигәнче, –
Шундук менеп җитәрлек!



Кулга оста, әйткән дә юк,
Талантлы безнең Хәлим;
Рәсемнәрен син дә күрсәң,
Шаклар катарсың әле!



Башы шәп эшли малайның –
Башлы малай шул Хәлим:
Әллә ниләр майтарып ул,
Укый дә белсә әле.



## Канатлы талант



**Айдар Хөсәнов** Казандагы 90 нчы мәктәптә укый. Буш вакытында чаңгы шуарга, әкиятләр укырга, ятлаган шигырьләрен сөйләргә ярата. Тагы... үзе дә шигырьләр яза.

Айдарның үзен тыңлыйк әле:

«Мин, зур үскәч, табиб булырга уйлыйм. Минем әнием авырый. Иң элек әниемне савыктырыр идем. Мин барча кешеләрнең дә сау-сәламәт булуларын телим. Табиб булу өчен бик тырышып укырга, бик күп белергә кирәк. Тырышып укысаң гына теләгеңә ирешеп була, дип уйлыйм».



## И әнием, әнием...

И әнием,әнием,
Беркайчан да авырма.
Гел елмаеп, көлеп тор –
Шундый улың барында.
Улың тиз үсеп җитәр,
Доктор булып та китәр.
Син әз генә түз инде,
Мин үскәнне көт инде!

## Йолдызлы җир


Бар минем бер хыялым –
Әкияттәге шикелле,
Ак болытка утырып,
Дөнья гизәсе иде:
Күктән йолдызлар чүпләп,
Җиргә сибәсе иде!



*Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА*




– Биим, биим, биим, биим...
Аякларым талганчы.
Тагын биим, тагын биим –
Магнитофон арганчы!
(Казан)




– «Эш эшлим», – дип торучы юк,
Мин генә гел эш кырам:
Бөтен өй эчен гел акка
Буярга уйлап торам!
(Питрәч)

Конкурс!
Мин бит бу?!







– Күзләреңнән һич кенә
Ала алмыйм күземне...
Бер күрүдә яраттырдың,
Кил, үбимче үзеңне!
(Әлмәт)




– Тәмле иде вәринҗәсе! –
Түзеп тора алмадым:
«Ә» дигәнче ялт иттердем –
Савыты да калмады...
(Чаллы)




– Бакчада кызарып
Пешкәннәр чияләр:
«Өзелеп сагындык,
Искәндәр», – дияләр.
(Казан)





Кыш уртасы гына булса да, ямьле җәйне сагына да башладык бугай. Кайбер яшь рәссамнарыбыз сагынуларын, сурәт итеп, кәгазьгә дә төшерә башлаганнар инде әнә...



*Рүзилә Фәткуллина, VI сыйныф. Әгерҗе районы, Ямурзино авылы.*



*Әдилә Нәфиева, 5 яшь. Казан.*



*Инсаф Гыйльманов, II сыйныф. Теләче районы, Шәдке авылы.*

# Игелекле Батырҗан

Яшәгән, ди, Батырҗан исемле малай. Бервакыт ул каз бәбкәләре саклагач, өенә кереп киткән. Шулвакыт күктә тилгән очып йөри икән. Ул төшкән дә, бер бәбкәне алып, менеп киткән. Батырҗанның бабасының киез итеге булган. Ул шул итекне киеп, тилгән артыннан менеп киткән һәм, тилгәнне куып тотып, бәбкәне алып төшкән. Бәбкәнең анасы Батырҗанга и рәхмәтләр укыган, и рәхмәтләр укыган, «Акыллы, игелекле булып үс, Батырҗан!» – дигән, ди.

*Гөлгенә Сәхәпова, 9 яшь. Мамадыш районы, Урта Сөн авылы.*

Мин җәйге каникулда Казанга апаларга кунакка бардым. Мин торган апалар күршесендә бер кыз бар иде. Аның әнисе – Сания, әтисе – Гариф, ә кыз үзе Бану исемле иде. Без ул кыз белән уйный башладык. Әмма уйнаганда ул минем белән урысча гына сөйләшә иде. Ул сөйләшсә дә, минем аның белән бик сөйләшәсе килми иде. Сүзләрен аңласам да, мин җавап кайтармый идем. Шуннан миннән: «Почему не отвечаешь?» – дип сорады. Мин аңа: «Синең белән русча сөйләшергә, мин бит – татар баласы», – дидем. Ул өенә кайткан да, әнисенә мин шулай дип әйткәнне сөйләп күрсәткән. Әнисе аңа: «Айсылу дөрес әйткән, – дигән. – Син дә бит татар баласы, аның белән татарча сөйләш», – дигән. Икенче көнне Бану уйнарга чыккач: «Исәнме, Айсылу!» – дип исәнләште. Шуннан соң без аның белән татарча гына сөйләшеп уйнадык.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

**Айсылу Шәфигуллина**, 10 яшь.
Кайбыч районы, Мөрәле авылы.

* * *

2002 елда минем әбиемнең әнисенә 100 яшь тула. Ул моңлы итеп барча догаларны укый, безгә теләкләр тели. Юкка гына җырламыйлар бит: «Яклый мине, саклый мине әнкәйнең догалары», – дип. Алар саклый безне, мин дә, догаларны өйрәнеп, үземнең балаларыма җиткерермен. Чөнки мин бит – татар баласы!



**Марсель Сәрвәров.**
Башкортостан, Сынташтамак авылы.

**Кадерле укучыбыз!**
**«Мин – татар баласы!» бәйгесенә хатлар килүен дәвам итә.**
**Синнән дә матур язма көтеп калабыз.**






# Өч аучы

***Француз халык әкияте***

Яшәгән, ди өч аучы. Икесе гел шәрә йөргән, өченчесенең бөтенләй киеме булмаган.

Өч аучыда өч мылтык, ди: икесе корылмаган, өченчесенең патроны юк икән.


Бервакыт болар бик-бик иртә торганнар да, ди, еракка, еракка, аннан соң ерак-ның да аръягына киткәннәр, ди.

Урманга җитәрәк, алар өч куян атып екканнар. Ике куянны куып тоталмаганнар, өченчесе качкан. Качканын киеме бөтенләй булмаган аучының кесәсенә салганнар.

– Аһ! Уһ! Иһ! – дигәннәр алар. – Бездән качып котылган куянны хәзер ничекләр итеп пешерәбез инде?

Өч аучы янә юлга кузгалган, ди.

Алар бик озак һәм бик ерак, тагын бик озак һәм бик ерак барганнар, ди.








Ниһаять, стенасыз, түбәсез, ишексез һәм тәрәзәсез, кыскасы, бернисез өй янына килеп җиткәннәр болар.

Өч аучы өч мәртәбә ишек шакыган: «Шык! Шык! Шык!»

Булмаган өйнең булмаган хуҗасы:

– Кем бар анда? Сезгә нәрсә кирәк?– дип дәшкән, ди.

– Хуҗа әфәнде, бездән качып котылган куянны пешерер өчен чүлмәк биреп тормассың микән? – дигәннәр аучылар.

– Аһ, аучы әфәнделәр, минем өч чүлмәгем бар: икесенең төбе юк, ә өченчесе бернигә дә ярамый! – дигән өй хуҗасы.

Их, бигрәкләр дә тәмле булды куян шулпасы!



*Рәссам Илдар НӘФИЕВ*



# Җүләр бүре

Бер көнне бүрегә тау өстендә бер Кәҗә тәкәсе очраган. Бүре әйткән тәкәгә:

– Хәзер мин сине ашыймын, – дигән.

Кәҗә тәкәсе әйткән:

– Мин карт инде, ашаганда тешләрең авыртыр, – дигән. – Син алай итмә, бар, тау төбендә авызыңны ачып көтеп тор. Мин тау башыннан чабып төшәрмен дә туп-туры авызыңа кереп китәрмен, – дигән.

Бүре, ярар, дип, тау төбенә төшеп киткән икән. Кәҗә тәкәсе бик каты чабып төшеп, Бүрене шундый каты сөзеп җибәргән. Бүре, башым ярылды бугай, дип тәгәрәп-тәгәрәп киткән.

Икенче көнне Бүре балалы бер Дуңгыз күргән. Бүре моның балаларын ашамакчы булган. Моны белгәч, Дуңгыз әйткән Бүрегә:

– Ярый, нихәл итмәк кирәк, ашасаң ашарсың инде. Әмма минем балаларым бик пычрак; әйдә, тегермән янына барыйк, мин сиңа аларны юып бирермен, – дигән.

Бүре моңа да риза булган. Менә алар тегермән янына килеп җиткәннәр. Дуңгыз Бүрегә әйткән:

– Син буаның артына төш, мин сиңа юып бирә торырмын, син ашый торырсың, – дигән.


Бүре, Дуңгызның сүзен тыңлап, буаның артына ук төшеп утырган. Шул арада Дуңгыз кинәт кенә арыкны ачып җибәргән, су шаулап килеп төшкән дә, Бүрене агызып та киткән.

## Бүре

Этләр семьялыгындагы иң зур ерткыч – бүре. Моннан дүрт миллион ел элек үк йорт этләре белән бүреләр ике төркемгә аерылган дип фаразлыйлар.

Бүре Татарстанның һәрбер районында диярлек бар. Алар урманнарда яши.

Зур соры бүренең авырлыгы 34тән алып 56 килограммга чаклы җитәргә мөмкин. Ата бүре ана бүрегә караганда шактый зуррак була.





*Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ*



Бүренең йоны бик озын, калын. Ул 5-6 сантиметрга чаклы җитә.

Бүренең гәүдә озынлыгы 2 метрдан артып китәргә мөмкин.

Елга бер тапкыр бүре үзенең тунын (йонын) алыштыра. Кыш көне йоны озынрак, калынрак була.


Бүренең койрыгы да озын. Йоклаган чагында ул койрыгы белән аякларын, борынын каплый, Әкияттә надан итеп сурәтләнсә дә, тормышта бүре бик акыллы һәм зирәк җәнлек.





# Сканворд







Башваткычларны **Илсөяр Гарипова** төзеде.

*Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ*

# Кроссворд

1. Шүрәленең әтисе.
2. Канатлы елан, Казанның символы.
3. Казан ханбикәсе.
4. Татарның милли бәйрәме.
5. Әкияттәге Сокның туганы.
6. Тукай, Җәлил, Туфан – ...

Кроссвордны дөрес чишсәгез, сары баганада татар классик шагыйрен табарсыз.





# Башваткычлар

1. Ормый-сукмый, үзе кешене җылата.

2. «Алма!» – дисәң дә, алалар.

3. Үлән арасында үсәм, алсуланып пешәм.

4. Агачтан биек, үләннән кечкенә.

5. Үзе шунда, үзе беленми, тынга беленә, күзгә күренми.

6. Каны бар, җаны юк.

7. Озын томшыклы, агачлар табибы.

8. Нинди яшелчә уңнан да, сулдан да бер төсле укыла.

9. Утлы да була, утсыз да.

10. Кош.

11. Җир астында алтын казык.

12. Үзе кып-кызыл, күлмәге ямь-яшел.

13. Озын чәчәсең, күзен җыеп аласың.







Җаваплар: 1. Суган. 2. Алма. 3. Җиләк. 4. Яфрак. 5. Һава. 6. Балан. 7. Тукран. 8. Кабак. 9. Күмер. 10. Песнәк. 11. Кишер. 12. Карбыз. 13. Бәрәңге.



Рәссам Светлана Ибраһимова

Башваткычны Ядкәр Габайдуллин (Буа районы, Кырык-Садак мәктәбе) төзеде.



Бу рәсемдә күпме чыршы, кош, сәгать сурәтләнгән? Кыш бабай, кар бабай һәм куянны да тап.

*Рәссам Максим ПОКАЛЕВ*

Журналның тышлыгындагы календарьны сызыкларыннан бөкләп, өй түбәсе рәвешендәге катыргыга ябыштырыгыз һәм өстәлегезгә бастырып куегыз.


Сәлават күпере

**1(143) — 2002**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ

1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
**Зиннур ХӨСНИЯР**

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Диләрә НӘҮРУЗОВА рәсемнәре.

**Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.**

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 10.1.2002 ел.
Басарга кул куелды 10.1.2002 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 14948 данә. Заказ Б-11.
Бәясе килешү буенча.



POINT®





**Гыйнвар**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Сиш. | 1 | 8 | 15 | 22 | 39 |
| Чәр. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Пән. | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| Җом. | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Шим. | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| Якш. | 6 | 13 | 20 | 27 | |

**Февраль**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 4 | 11 | 18 | 25 |
| Сиш. | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| Чәр. | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| Пән. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Җом. | 1 | 8 | 15 | 22 | |
| Шим. | 2 | 9 | 16 | 23 | |
| Якш. | 3 | 10 | 17 | 24 | |

**Март**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 4 | 11 | 18 | 25 |
| Сиш. | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| Чәр. | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| Пән. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Җом. | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Шим. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Якш. | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |

**Апрель**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Сиш. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Чәр. | 3 | 10 | 17 | 24 | |
| Пән. | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Җом. | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| Шим. | 6 | 13 | 20 | 27 | |
| Якш. | 7 | 14 | 21 | 28 | |

**Май**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| Сиш. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Чәр. | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Пән. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Җом. | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| Шим. | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Якш. | 5 | 12 | 19 | 26 | |

**Июнь**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 3 | 10 | 17 | 24 |
| Сиш. | | 4 | 11 | 18 | 25 |
| Чәр. | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| Пән. | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| Җом. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Шим. | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Якш. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |

**Июль**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Сиш. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Чәр. | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| Пән. | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Җом. | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| Шим. | 6 | 13 | 20 | 27 | |
| Якш. | 7 | 14 | 21 | 28 | |

**Август**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| Сиш. | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| Чәр. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Пән. | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Җом. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Шим. | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| Якш. | 4 | 11 | 18 | 25 | |

**Сентябрь**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Сиш. | 3 | 10 | 17 | 24 | |
| Чәр. | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Пән. | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| Җом. | 6 | 13 | 20 | 27 | |
| Шим. | 7 | 14 | 21 | 28 | |
| Якш. 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | |

**Октябрь**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Сиш. | 1 | 8 | 15 | 22 | 39 |
| Чәр. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Пән. | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| Җом. | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Шим. | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| Якш. | 6 | 13 | 20 | 27 | |

**Ноябрь**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | | 4 | 11 | 18 | 25 |
| Сиш. | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| Чәр. | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| Пән. | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| Җом. | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| Шим. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Якш. | 3 | 10 | 17 | 24 | |

**Декабрь**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дүш. | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| Сиш. | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| Чәр. | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| Пән. | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| Җом. | 6 | 13 | 20 | 27 | |
| Шим. | 7 | 14 | 21 | 28 | |
| Якш. 1 | 8 | 15 | 22 | 29 | |

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953